ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Тынычлык урамы, 100а йорт,
Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 30 » сентябрь 2016 ел №10

## Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2017 елда Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1, 2 группадагы инвалидлардан) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - авылларда юлларны төзекләндерү (вак таш) җәю: Кышкар, Симетбаш авылларында | 162 600 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Урамнарның яктырту челтәрен ремонтлау | -яктырткыч лампаларны алыштыру: Иске Кишет, Кышкар авыллары | 8 000 |
| 3 | Җирлектә халыкны су белән тәэмин итү | -скважина өчен насос алу: Иске Кишет авылы | 7 000 |
| | | | 177 600 |

әйе

юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт, Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а йорты.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов